МИНИСТЕРСТВО
ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
УПРАВЛЕНИЯ,
ИНФОРМАЦИОННЫХ
ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН
ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ
ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ
ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.02.2022 Казан ш. № п/36

«Минем субсидияләр»
мәгълүмат системасы турында
нигезләмә раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасын төзү турында» 2020 елның 2 ноябрендәге 986 санлы карарын гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасы турында кушымтада бирелгән нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына, шулай ук «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасы эшен оештыруда катнашучы башка оешмаларга әлеге боерык белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасы турында нигезләмә раслау хакында» 2020 елның 13 ноябрендәге п/445 санлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

Министр А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2022 елның 17 февралендәге п/36 санлы боерыгы белән расланды

**«Минем субсидияләр» мәгълүмат системасы турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Минем субсидияләр» (алга таба – Система) мәгълүмат системасы эшен оештыру тәртибен билгели.

1.2. Система программа-аппарат чаралары, мәгълүмат базалары, шулай ук электрон исәпләү машиналары, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар өчен программалар комплексы булып тора, шулай ук мәгълүмат базаларында булган мәгълүмат һәм аны эшкәртә торган мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүмат чаралары тупланмасыннан гыйбарәт.

## 2. Терминнар һәм билгеләмәләр

2.1. Ярдәм – кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм башка затларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган ярдәм, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле булган башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә башка вәкаләтле оешмалар тарафыннан бәйгеләр уздыру.

2.2. Системаның дәүләт заказчысы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы яисә эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштырганда Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы булып торган дәүләт учреждениесе.

2.3. Системаның операторы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы яисә Системаны эшләтү, шул исәптән аның базасындагы мәгълүматны эшкәртү эшчәнлеген башкаручы дәүләт учреждениесе.

2.4. Башкаручы – дәүләт яисә муниципаль хакимиятнең башкарма органы һәм ярдәм күрсәтүгә вәкаләтле башка оешмалар.

## 3. Системаны оештыру максатлары

Система кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм башка затларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар тарафыннан ярдәм итү эшләрен цифрлаштыру

максатларында, шулай ук, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле булган башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә башка вәкаләтле оешмалар тарафыннан оештырылган бәйгеләрдә катнашу өчен электрон рәвештә гаризалар кабул итүне тәэмин итү максатларында төзелде.

## 4. Системаны куллану

4.1. Системадан ярдәм күрсәтүгә дәгъва белдерүче затлар һәм Башкаручылар файдалана.

Системага керү Система операторы тарафыннан билгеләнә торган бурычларны бүлү һәм вәкаләтләрне мөмкин булганча азайту калыбы буенча рольләр системасы нигезендә аутентификация һәм авторлаштыру чараларын кулланып гамәлгә ашырылган.

Ярдәм күрсәтүгә дәгъва белдерүче затлар тарафыннан Системадан файдалану «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайт (яки сайтлар) аша, шулай ук Система операторы тарафыннан билгеләнә торган электрон исәпләү машиналары (кәрәзле телефоннар, смартфоннар) программалары аша тәэмин ителә.

Башкаручылар тарафыннан Системадан файдалану мөмкинлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайт (яки сайтлар) аша тәэмин ителә һәм Башкаручыларның гаризалары нигезендә Система операторы тарафыннан бирелә.

Башкаручыга Системадан файдалану мөмкинлеге Татарстан Республикасының ярдәм күрсәтү тәртибен билгели торган тиешле норматив хокукый акты белән ярдәм күрсәтү турында мөрәҗәгатьне Системадан файдаланып, электрон рәвештә җибәрү мөмкинлеге каралган очракта бирелә.

Башкаручыларга Системадан файдалану мөмкинлеген бирү турындагы гаризаларның үрнәкләре, исәпкә алу язуларын үзгәртү, исәпкә алу язуларын куллануны чикләү рәвешләре Система операторы тарафыннан билгеләнә.

4.2. Система, Татарстан Республикасының мондый ярдәм күрсәтү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актларында каралган очракларда, Башкаручылар тарафыннан ярдәм күрсәтү максатларында кулланылырга тиеш.

4.3. Системада түбәндәге эшләрне үтәп була:

Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган ярдәм чаралары белән танышып чыгу;

Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган ярдәм чараларын шунда ук беренчел рәвештә сайлау;

ярдәм күрсәтү турында, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле булган башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә башка вәкаләтле оешмалар тарафыннан оештырылган бәйгеләрдә катнашу өчен гаризаны да кертеп, шул исәптән башка мәгълүмат системаларыннан алынган мәгълүматтан файдаланып, электрон рәвештә мөрәҗәгать юллау;

Система ярдәмендә ярдәм күрсәтү турында мөрәҗәгать белән эшләү дәрәҗәсен күзәтеп тору;

Башкаручыларның хезмәткәрләре өчен шәхси кабинет;

Система операторы тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин булган башка төрле гамәлләр.

4.4. Системада башкарып була торган гамәлләр Система операторы тарафыннан билгеләнә, аның тасвирламасы Системага карый торган техник документларга кертелергә тиеш.

4.5. Техник документлар Система операторы тарафыннан, шул исәптән, дәүләт контрактлары нигезендә башкаручыларны (подрядчыларны) җәлеп итеп, төзелә.

## 5. Система белән үзара багланыш

5.1. Система белән үзара багланышта торучы затлар:

дәүләт заказчысы;

Система операторы;

Башкаручы;

ярдәм күрсәтүгә дәгъва белдерүче физик һәм юридик затлар.

5.2. Дәүләт заказчысы Системага техник ярдәм күрсәтү, Системаны һәм аның элементларын модернизацияләү һәм башка эшләр (хезмәтләр күрсәтү) буенча эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) максатларында подрядчыларны (башкаручыларны) билгеләнгән тәртиптә билгели.

5.3. Система операторы:

Системаны эшләтү буенча эшчәнлек башкара;

шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатларын һәм эшкәртелергә тиешле шәхси мәгълүматларның составын, шәхси мәгълүматлар белән башкарыла торган гамәлләрне (операцияләрне) килештерә;

Система белән мәгълүмат-технологик багланышка һәм мәгълүмат алу һәм бирү тәртибенә карата таләпләрне билгели;

Башкаручы хезмәткәрләренең Системаны кулланып эшләү тәртибен билгели торган кагыйдәләрне килештерә;

Башкаручыларга, шулай ук ярдәм күрсәтүгә дәгъва белдерүче физик һәм юридик затларга Системага керү мөмкинлеген бирә;

Системаны булдыру, үстерү һәм техник яктан тәэмин итү, шулай ук анда эшкәртелә торган мәгълүматны саклау буенча чаралар үткәрелүен тәэмин итә;

шәхси мәгълүматларның сер булып саклануын һәм аларны эшкәрткәндә шәхси мәгълүматларның куркынычсызлыгын тәэмин итә;

Системаның һәм аның составына керә торган аерым элементларның эшләвен тәэмин итүче программа тәэминатының, сервер һәм челтәр җиһазларының өзлексез эшләвен гамәлгә ашыра.

5.4. Башкаручы:

Системада эшләү өчен боеру акты нигезендә хезмәткәрләрне (алга таба – җаваплы хезмәткәрләр) ачыклый һәм билгели;

җаваплы хезмәткәрләр белән Системада эшләү тәртибе, шәхси мәгълүматларны һәм сер булып саклана торган башка мәгълүматны саклау

кагыйдәләре һәм чаралары белән таныштырып чыгуны күздә тоткан инструктажны уздыра;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган очракларда, Системадан файдаланып ярдәм күрсәтүне тәэмин итә;

Системага кертелә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм актуальлеген тәэмин итә;

шәхси мәгълүматларның сер булып саклануын һәм аларны эшкәрткәндә шәхси мәгълүматларның куркынычсызлыгын тәэмин итә.

5.5. Системадан Башкаручылар, ярдәм күрсәтүгә дәгъва белдерүче физик һәм юридик затлар тарафыннан файдалану шартлары Оператор тарафыннан билгеләнә.

5.6. Система операторы Системада эшләү өчен җаваплы хезмәткәрләрне билгеләү һәм алар белән инструктаж үткәрүне тикшерүдә тотарга хокуклы.

---